Саттарова М.Р., ТГГПУ

Работа поддержана грантом РГНФ, проект № 11-14-16029а/В
“Историко-лексикографическое описание лексики материальной культуры татарского языка”

## Элементы материальной культуры в религиозной лексике

**Резюме.** Настоящая статья посвящается изучению отражения материальной культуры в религиозной лексике татарского языка. Вопрос рассматривается на материале татарских паремий, данных толкового и этимологического словарей.

**Ключевые слова**: материальная культура, религиозная лексика, этимологическое описание, татарский язык

## Дини лексикада матди мәдәният элементлары

Телнең сүзлек байлыгы төрле максатлардан чыгып анализлана торган ярус булып санала. Лексика тел тарихына, халык тарихына, этнографиясенә һ.б. караган мәсьәләләрне өйрәнү өчен чыганак булып кына калмыйча, экстралингвистик шартларга бәйле үзгәрешләрне дә үзендә туплап, үткәндәге реалияләрне бүгенгесе белән чагыштырырга мөмкинлек бирә. Тикшеренү нәтиҗәләренең төгәллеге лексик берәмлекләрне хәзерге халәтендә генә өйрәнеп калмыйча, аларның буыннан-буынга үзгәртелмичә тапшырылып килгән мәкаль-әйтемнәрдә кулланылышын барлау белән дә бәйле. Тотрыклылык ягыннан бәяләгәндә, сүзләр әйләнә-тирәлектәге әйбер, күренешләр белән тыгыз бәйләнештә тора һәм вакыт узу белән теге яки бу берәмлеккә карата яңа, архаик, тарихи сүзләр төшенчәсе кулланылуы табигый. Шул ук вакытта телебездә бик борынгы чорларда ук кулланылышта булган предмет, күренешләрне атый торган сүзләр кулланыла. Үзгәрмичә, меңъ еллар дәвамында халык телендә сакланып килә торган мондый лексик

берәмлекләр билгеле бер өлкәләргә карый һәм халыкның матди мәдәниятен өйрәнү өчен тирән эчтәлекле чыганак булып тора.

Халыкның бөтенлеген, бердәмлеген саклауда аеруча әһәмиятле урын тоткан күренеш – дин. Татар халкының тарихта билгеле булган кадәр яшәү дәверендә динле булганлыгы билгеле. Бүгенге дәвердә татар халкында ислам дине торгызылу күзәтелә. Шуның белән бәйле үткән гасырда искергән сүзләр буларак бәяләнгән лексика бүген янәдән актив кулланыла. Дин өлкәсенә караган, аның рухи һәм матди эчтәлеген чагылдыра торган берәмлекләр нәкъ менә алда искәртелеп үткән тотрыклы катламга карый. Моның шулай икәнлеген раслау өчен берничә лексик берәмлекнең бүгенге татар телендә кулланылышы, этимологиясе, аларның мәкаль-әйтемнәрдә теркәлгән очраклары барлана.

Дини лексиканы анализлаган вакытта бик тирән катламнарга керергә мөмкин. Тарих, мәдәният, этнография кебек киң колачлы тикшеренү өлкәләре белән бергә тел белеме дә халык милли үзенчәлекләрен, менталитетын тасвирларга мөмкинлек тудыра. Татар халкының тарихы белән тыгыз бәйле булган әлеге лексик берәмлекләр турыдан-туры аның тормыш рәвеше, яшәешенең этномәдәни үзенчәлекләрен чагылдыра торган элементлар булып тора. Тормыш рәвешен чагылдыра торган катлам буларак, дини лексика киңкырлы. Әлеге мәкаләдә дини атрибутиканы белдерә торган *Коръән, намазлык, тәсбих, комган* лексик берәмлекләрне тарихи-лексикографик тасвирлау максаты куелды.

“Татар теленең аңлатмалы сүзлеге”ндә һәм “Татар теленең кыскача тарихи-этимологик сүзлеге”ндә Коръән, намазлык, тәсбих, комган сүзләренә түбәндәге аңлатма бирелгән:

*Коръән* – гар. Мөселманнарның изге китабы (Аллаһы Тәгаләнең кешеләргә дөрес яшәр өчен үзенең илчесе Мөхәммәт пәйгамбәр аша җибәргән сүзләре, кануны) [ТТАС, 2005: 283]. Коръәнне мөселманнар олылап Коръән Кәрим дип йөртәләр. Гарәп телендә ул яттан уку, яттан сөйләү мәгънәсенә ия [Ислам. Белешмә-сүзлек, 1993 :69].

Бу китап татар халкы тормышында мөһим урын алып торган. Ул – Аллаһ Тәгаләнең барлыгын һәм берлеген танып яши торган кеше өчен кануннар җыентыгы функциясен башкара. Моны раслап, “Шайтанга кирәк булса, Коръәннән дәлил китерә” дигән мәкальне әйтергә мөмкин [Исәнбәт, 2010 (3 т): 772]. Ягъни, акланыр өчен үзенә каршы булса да, Коръәннән дәлил алу мөмкинлеге аңлашыла. Кыямәттә кешеләр үзләре кылган гөнаһлары өчен шайтанны гаепләячәкләр, ә шайтан аларга мәҗбүри рәвештә явызлык эшләтмәве, ә начарлыкны яхшылык итеп күрсәтергә тырышуын раслау өчен Коръәнгә мөрәҗәгать итә.

Татар халкында әлеге китап, аны уку белән бәйле аерым тәртипләр формалашкан. Коръән Кәрим чиста, балалар кулы җитми торган урында кадерләп саклана, аны кулга алыр алдыннан тәһарәт алу мәҗбүри. Коръәнне уку өчен гарәп телендә укый белү генә җитми, тәҗвид – Коръән Кәримне уку кагыйдәләрен белү зарур. Коръән Кәримне Аллаһ Тәгалә ризалыгы өчен дөрес итеп укыган кешегә аның һәр хәрефе саен савап языла, диелә. Санап үтелгән һәм башка шартлар татар кешесен гасырлар дәвамында физик чисталык, рухи яктан тотрыклылыкта яшәүгә этәргән. Ә иң мөһиме – татар кешесе яза белмәгән очракта да, укырга өйрәнеп, белем-мәгърифәткә омтылган. Әлеге фактор халыкның рухи һәм матди мәдәнияте үзенчәлекләрен, менталитетын формалаштыруда зур урын алып торган.

*Комган* – Гадәттә җиз һ.б. төрле калайдан эшләнә торган махсус формадагы, тоткалы һәм борынлы су савыты (элек-электән бирле ритуаль юыну-тәһарәт алу өчен файдаланыла) [ТТАС, 2005: 271].

Тарихи-этимолоик сүзлектә “*комган* – гом.тк. *қумқан* (комган) киң таралган сүздән бор. чыгт. *кумка* “кувшин”, якут. *хомоус* “чүмеч”, фарсы-таҗ. *хуҗ, хумб*, бор. ирани *хи ва* (*хумба*) “комган”, рус. диал. *кумка* “стакан”, грек. *хубба*, рус. *куб* (*кубок*) “комган”, диелә [Әхмәтьянов, 2001: 112]. Тасвирламадан аңлашылганча, комган төрле халыкларда кулланылган. Гомумтөрки телдә киң таралган булуы аның төркиләрдә бик күптәннән кулланылышта йөрүе хакында сөйли булса кирәк. Матди мәдәният элементы

буларак бу предмет атамасы әдәби әсәрләрдә дә үз урынын алган. Мәсәлән, Э.Шәрифуллина “Мәдхия” шигырендә мондый юллар бар:

*Дөнья тулы сер, илаһым*
*Әйтик, гади бер комган.*
*Эчләренә госел кояр*
*Көмеш сыман су тулган.*
*Энҗе-мәрҗән салып кайчак*
*Җир астына күмгәннәр.*
*Ат менгән сугышчы ирнең*
*Иярenә элгәннәр.* [Шәрифуллина, 2003: 157]

Әлеге юллардан комганның татар халкы өчен көндәлек тормышта мөһим предмет булганлыгы аңлашыла. Ул – чисталык, пакълек, сәламәтлек чыганагы. Фикерне раслый торган мәкаль: Мөселманлык икедер: комган белән пәкедер [Исәнбәт, 2010 (3 т.): 773]. Мөселман булуның нигезе – чисталык: пәке белән кырына, комган белән юына, тәһарәт ала.

*Намазлык* – дини. Намаз укыганда кулланыла торган махсус пакъ җәймә [ТТАС, 2005: 380]. Р.Г.Әхмәтьянов хезмәтендә намазлык сүзе каралмый. Әмма бу сүзнең татар телендә намаз сүзенән ясалганлыгы ачык. Намаз – “намаз, молитва” – фарсы. *намаз* “намаз” сүзеннән; бор. фарсы. *namazh* > авеста. *nemanh* (*неманһ*) “намаз; баш иеп сәламләү”. Ислам динен кабул итү гарәп теле белән бәйле булса да, гыйбадәтнең бер төре буларак намаз уку гарәп телендә salat сүзе белән белдерелә һәм бу сүз татар телендә кулланылышка кермәгән. Татарларда элегрәк гади тукымага чәчәкләр, төрле орнаментлар төшерелгән чигүле намазлыклар кулланылышта булган. Бүгенге көндә исә келәм кебек ясалган намазлыклар киң кулланылышта йөри.

*Тәсбих* – гар. 1) иск. Алланы мактау сүзе; 2) Җепкә тезелгән йөз төймәдән гыйбарәт җайланма – аның һәр төймәсен Аллага мактау сүзен әйтеп артка шудыралар һәм шулай итеп зекер итүдә билгеле бер ритмга, тәртипкә ирешәләр [ТТАС, 2005: 585].

Кызганычка, татар теленең тарихи-этимологик сүзлегендә Коръән һәм тәсбих сүзләренең килеп чыгышына фәнни тасвирлама бирелми. Дини лексиканың без карап киткән дүрт берәмлегенең бары берсе генә татар телендә ныклы урнашып, кулланылышка кереп киткән. Калган өчесе гарәп-фарсы телләреннән кабул ителгән һәм чикләнгән кулланылышка ия. Шулай да бу сүзләр актив рәвештә яңа сүзләр ясауда катнашып, телебезне тагын да баеткан. Мәсәлән, *коръәнхафиз*, *комганлык*, *намаз-нияз*, *намазчыл, тәсбихче* кебек лексик берәмлекләр; *Коръән белән ант итү, Коръән уку, җиз комган, намаз иясе, тәсбих анасы, тәсбих мулласы, тәсбих тарту, тәсбих әйтү* кебек тотрыклы берәмлекләр кулланылу шуны раслый.

Халыкның дөнья турында фикерләве, тормыш алып бару рәвеше, аны чолгап алган реалияләр сөйләмдә һәм язма чыганакларда теркәлә һәм буыннан-буынга тапшырыла бара. Дин теләсә нинди халык тормышының аерылгысыз өлеше булганга күрә, дини лексика да көндәлек тормыш-көнкүрешнең мөһим өлкәсен – матди мәдәниятның бер өлешен тәшкил итә.

**Искәрмәләр.**

Әхмәтьянов Р.Г. Татар теленең кыскача тарихи-этимологик сүзлеге / Р.Г.Әхмәтьянов. – Казан: Татар.кит.нәшр., 2001. – 272 б.

Исәнбәт Н. Татар халык мәкальләре: мәкальләр җыелмасы: 3 томда. 3-нче т./ Нәкый Исәнбәт. – 2-нче басма. – Казан: Татар.кит.нәшр., 2010. – 799 б.

Ислам. Белешмә-сүзлек / Төз.: З.Шәфигый. – Казан: Татар.кит.нәшр., 1993. – 191 б.

Татар теленең аңлатмалы сүзлеге / Баш.ред.: Ф.А.Ганиев. – Казан: Матбугат йорты, 2005. – 848 б.

Шәрифуллина Э. Уйлы еллар / Э.Шәрифуллина. – Казан: Татар.кит.нәшр., 2003. – 287 б.